# РАЙОН СУЛЫШЫ

## ...рмыш юлы уза



ә кичә. Еш булмаса да, сугыш хатирәләрен искә төшергәли.

Кызыл Армиягә 1939 елны ук алына. Аннан Бөек Ватан сугышы башлана. Сугыш юлын танк частендә башласа да, танкист булып китә алмый. Танкларны бомбага тоталар, яңаны заводтан алып кайту мөмкин булмый. Артиллериядә дә бик кыска вакыт кына хезмәт итә. Ә аннан җәяүле була – дошманга каршы пехотада сугыша. 1944 елны бик каты яралана, 4 ай ярым госпитальдә ята. Аннан өенә кайтарып җибәрәләр.

Туган авылына күп орден-медальләр тагып кайта ул. Биредә Гөлбикә Камалетдин кызына өйләнеп, бик матур, күпләр көнләшерлек гаилә корып, тормыш юлы узалар. 12 балалары туа, кызганычка каршы өчесе вафат. Инде җәмәгате дә бакыйлыкка күчкән.

– Бүгенгедән канәгать мин: балаларымның уңганлыгын күреп куанам. Тормыш хәлләре әйбәт: ашарга-эчәргә бар, пенсия җитәрлек, – ди юбиляр-ветеран.

## Күңгәр мәктәбендә – Россия көне

чара



интернет-күзәтү

## Казахстанда террор

Казахстанның Актүбә шәһәрендә берничә дистә кеше, башта ике корал кибетен талап, аннары автобусны кулга төшереп, хәрби бүлеккә һөҗүм итәргә маташкан. Әлеге хәлдән соң калада террорның иң куркыныч – "Кызыл" дәрәҗәсе игълан ителгән. Шәһәрдәге телеканаллар һәм смс аша халыкны өйләреннән чыкмаска чакырганнар. Бәхеткә, кораллы кешеләр ниятләренә ирешә алмаган. Ләкин аларның бер өлеше качып китәргә өлгергән. Атыш вакытында 17 кешенең гомере өзелгән, 22 кеше яраланган. Хокук сакчылары фикеренчә, һөҗүм итүчеләр - традицион булмаган диннең радикал юнәлешендәге затлар дип фаразлана.

## Араларында бай татар яшәвен белми калганнар

Новосибирскида ФСБ хезмәткәрләре ришвәттә шикләнелгән Илгиз Гарифуллинны тоткарлаган. Ул Росрезервның Себер бүлеге җитәкчесе урынбасары булып эшләгән.

43 яшьлек Гарифуллин үтә дә зиннәттә яшәргә яратуы белән ФСБ һәм тикшерү идарәсе хезмәткәрләрен шаккатырган, дип яза "Комсомольская правда". Тикшерү фаразлавынча, 2015 елның октябрь-декабрендә ябык бәйгедә җиңү яулауда булышкан өчен аңа ришвәт – «Порше Кайен» машинасын биргәннәр. Бәйге бер генә ширкәт ота ала торган итеп оештырылган. Нәтиҗәдә, "Ленпромтрансроект" ширкәтеннән кала берәү дә анда катнаша алмаган.

Гарифуллинның өендә тентү узган. Түрә Эрбет урамындагы кыйбатлы бистәдә яшәгән. Бер кыйбатлы фатиры – кызы, икенчесе – 200 метрлы таунхаус һәм машина куя гаражы җәмәгатенең әнисе исеменә язылган булган. Тикшерүчеләрне Гарифуллинның машина паркы гаҗәпкә калдырган. Анда дистәгә якын затлы автомобиль булган. Тикшерүчеләр өйдә 100 миллион сум акча тапкан.

Түрә ауга йөрергә яраткан. Тикшерүчеләр аның өендә берсе-берсе ярты миллион сумлык кыйммәтле ау мылтыклары да тапкан. Ауга йөрү өчен ул сәгатенә 110 мең сум түләп вертолет арендалаган, тау тәкәләре (архар) ауларга яраткан, дип яза басма.

Росрезерв түрәсе ел да декларациясендә 500 мең сум акча эшлим дип күрсәтеп килгән. Хезмәт хакы 43 мең сум булган.

җыртыклар